Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАРЫ

16 июнь, 2023 ел № 68

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясендә янгын сүндерү, һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен көчләрне һәм чараларны җәлеп итү тәртибе турында

Язгы-җәйге чорда янгын куркынычы арту сәбәпле, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 2004 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2023 елның 30 мартындагы 376 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясе чикләрендә янгын сүндерү, һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкаруны оештыруны камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясендә янгыннарны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкаруга янгыннан саклау көчләрен һәм чараларын, оешмаларны һәм халыкны җәлеп итүнең түбәндәге тәртибен билгеләргә:

1.1. Янгын саклау бүлекчәләренең янгын сүндерүгә һәм аларны юкка чыгаруга чыгуы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясендә янгыннарны сүндерү буенча көчләрне һәм чараларны җәлеп итү планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.2. Авыл җирлегендә янгыннарны сүндерүне һәм авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкаруны оештыру гамәлләре янгын сагының һәм янгын урынына башка хезмәтләрнең үз вакытында килеп житүен һәм янгын сүндерү чараларының житәрлек күләмдә булуын гамәлгә керткәннән соң юлларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясендә янгын сүндерүне оештыру буенча төп документларның рәвешләрен расларга:

- «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясендә янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен көчләрне һәм чараларны җәлеп итү тәртибе турында нигезләмә» (1 нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясендә янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен көчләрне һәм чараларны җәлеп итү исемлеге» (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р.Сәйфетдинов